Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре “Катнаш төрдәге 3 нче “Айсылу” балалар бакчасы

Раслады:

МББМБУ РТ Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре “Катнаш төрдәге 3 нче “Айсылу” балалар бакчасы мөдире

__________ Р.Х. Исламова

“28” 2025г.

Приказ №39

Педагогик киңәшмәдә

кабул ителде

Беркетмә № 1

“28” 08.2025

**Өстәмә белем бирү буенча зурлар төркемендә “Нәни артистлар”**

**театр түгәрәге**

**ПРОГРАММАСЫ**

**2025-2026 нчы уку елы**

Төзеде:

югары квалификацион категорияле

тәрбияче Бәдертдинова Л.Җ.

# Аңлатма язуы

Ел саен балалар бакчасына яңа балалар килә. Аларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзләрен тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенң әһәмияте зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә-юнь, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә шулар аша дөньяда яшәргә, үзенең мөгаләмәләрен төзергә өйрәнә. Бу исә баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес һәм матур сөйләшә булуын таләп итә. Сәхнәләштерүдә катнашып, балалар төсләр, образлар аркылы тирә-юнь белән танышалар, ә сораулар аларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә.

Акыл үсеше белән сөйләм теленеә үсеше нык бәйләнгән. Персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләгәндә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләнә. Башкарылачак роль баланы чиста, аңлашырлык итеп сөйләвен сорый. Сәхнәләштерү барышында, бала геройлары өчен кайгыра, үзен алар урынына куя, булышу юлларын таба, яхшылык һәм явызлыкка үзенең карашын күрсәтә.

Соңгы елларда тормышыбызңа, яшәешебездә бара торган үзгәрешләрнең берсе - туган халкыбызның милли мәдәниятенә, рухи дөньясына игътибар итү. Шуны искә алып, без дә балалар бакчасында халкыбызның матур сәнгате – театр белән балаларны таныштыруны, шул матурлыкны тудырырга омтылыш уятуны төп бурыч итеп куябыз.

Театр нәниләрне сихри дөньяга  алып керә, аларның сәләтен ачарга ярдәм итә, иҗади фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерә, актерлык осталыгына өйрәтә, эстетик һәм әхлакый тәрбия бирә. Театраль педагогик ысулларын куллану балаларның хәтерен, игътибарын, күзаллау сәләтен, сөйләм чисталыгын, үзләренең тавышлары белән идарә итү мөмкинлекләрен, шулай ук коллективта үз-үзләрен тоту, кыюлык сыйфатларын үстерергә ярдәм итә.

Максат: сәхнәләштерү эшчәнлеге чаралары аша балада иҗади шәхес формалаштыру.

Сәхнәләштер эшчәнлеге үз алдына түбәндәге бурычларны куя:

- театр, сәхнә турында күзаллауларын  баету;
- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксыну уяту;
- балаларның сүз байлыгын үстерү;
- дөрес аваз әйтелешен тәрбияләү;
- игътибар, хәтерне камилләштерү;
- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация кебек тәэсир итү чараларын кабатлау теләге тудыру;
- балаларны сәхнәдә үзләрен иркен, курыкмыйча тотуга этәрү;
- театрда дөрес тоту күнекмәләренә ирешү.

Түгәрәкне үткәрү формалары: әңгәмәләр, теартлар, мультфильмнар карау, җырлы-биюле, сюжетлы-рольле, хәрәкәтле, дидактик уеннар, репликалар өйрәнү, спектакльләр, инсцеенировкалар кую, әкиятләр, шигырьләр уку, ятлау.

Программа дәвамлылыгы: сентябрь - май. Яшь чикләве: 5-6 яшь. Түгәрәк атнага 1 тапкыр уздырыла. Түгәрәк эше 25 минут дәвам итә.

| Эшчәнлекнең темасы | Максат һәм бурыч | Методик күрсәтмәләр |
| --- | --- | --- |
| **октябрь** | | |
| 1.”Нәрсә ул театр?”<br>Театр төрләре. | Театр сәнгате һәм аның төрләре белән таныштыру. Театр , сәхнә турында күзаллауларын баету. | Аз хәрәкәтле уен “Яхшы кәеф”<br>Театр , сәхнә турында әңгәмә.<br>Презентация карау “Театр төрләре”<br>Сюжетлы-рольле уен “Театрга бару”<br>Хәр. уен “Кояш” ( К.В. Закирова “Уйный-уйный үсәбез”, 160б.)<br>Видеоэкскурсия “Театрда” |
| 2.А. Алиш-әкият остасы. “Чукмар белән Тукмар” әкияте. | А. Алиш, аның әкиятләре белән таныштыру. Уйлау сәләтен үстерү, сулыш алуны ныгыту. | Язучы портреты һәм әкиятләре буенча иллюстрацияләр карау.<br>Табышмак әйтү:<br>“Баша –тарак,<br>Койрыгы- урак (уракның рәсемен күрсәтү, аңлату).<br>Кычкыртып быргысын<br>Уята барысын. (Әтәч)<br>Сулыш гимнастикасы “Тавык” (канат кагу вакытында әкрен генә сулыш алу)<br>Җырлы-биюле уен “Чебиләр зарядкасы”<br>“Чукмар белән Тукмар” мультфильмын карау.<br>Әкият буенча сөйләшү. |
| 3. А. Алиш “Чукмар белән Тукмар” әкияте. | Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү. Авазны дөрес әйтүгә ирешү, дикцияне ныгыту. Геройларны барлау, сүзләрне өйрәнә башлау. | Аваз әйтелешенә күнегү “Быргы”, “Тәмле варенье”<br>“Ч” авазы әйтелешенә күнегүләр:<br>“Ча-Ча- без йөрибез бакчага.<br>Че-че- миңа әкият сөйләче.<br>Рәсемнәр буенча әкият эчтәлеген сөйләү.<br>Җырлы-биюле уен “Башаклар”.<br>Хәр уен “Тычканнар”.<br>Рольләрне башкару. |

| | | |
|---|---|---|
| 4. А. Алиш “Чукмар белән Тукмар” әкияте. | А. Алиш әсәрләренә кызыксыну уяту, язучы иҗаты аша балаларда уңай сыйфатлар тәрбияләү. Ритм, тизлек, координация, пластика, хәрәкәтчәнлекне камилләштерү. | Сулыш алу күнегүләре: “Капкага керт”.<br>Ритмопластика: куркак тычкан, батыр песи, горур әтәч, шаян чебиләр.<br>Хәрәкәтле уеннар “Мәче-тычкан уены”.<br>Җырлы-биюле уен “Башаклар”, “Шаян тычканнар”<br>“Чукмар белән Тукмар” әкияте буенча репетиция. |
| **ноябрь** | | |
| 5. А. Алиш “Чукмар белән Тукмар” әкиятен сәхнәләштерү. | Сәхнәләштерү осталыкларын һәм сулыш алу, сөйләм аппаратын үстерү. Күзаллау, фикерләү сәләтен арттыру. | “Чукмар белән Тукмар” әкиятен сәхнәләштерү. |
| 6.Костюмер бүлмәсендә. | Костюмер һөнәре белән таныштыру. | Презентация карау: “Театр һөнәрләре”<br>Әңгәмә.<br>Дид уен “Киемне дөрес сайла!”<br>Уенлы күнегү “Мин образга керәм” (костюмнар кию |
| 7.”Башак” . Украин халык әкияте. | ”Башак” . Украин халык әкияте.Көз ел фасылы турында белемнәрен ныгыту. Пантомима күнекмәләре бирү өстендә эшне башлау.<br>“Кем эшләми- шул ашамый” мәкаленә нигезләнеп, балаларда хезмәт тәрбиясе бирү. | Әңгәмә. Табышмакка җавап табу. “Көз”<br>Уенлы күнегү. “Яшелчәне бир”, “Кайнар бәрәңге”.<br>Җырлы-биюле уен “Күрсәт әле , үскәнем” (Салаватики)<br>Украин халык әкиятен карау.<br>Сорау-җавап.<br>Мәкаль турында фикер алышу. |
| 8.”Башак” . Украин халык әкияте. | ”Башак” . Украин халык әкияте белән таныштыруны дәвам итү. Әкият геройларын билгеләү, рольләрне бүлү. Тамаша уйнау осталыкларын һәм диалогик сөйләмне үстерү. Балаларның гәүдә хәрәкәтләрен камилләштерү. Образлы фикерләүләрен үстерү. | Сөйләм аппаратын үстерүгә күнегү: “Насос”<br>Табышмакларга җавап табу.<br>Уенлы күнегү “ Мине таны”<br>Уен “Тылсымлы таяк” : кояш, яңгыр, әтәч, комбайн, тычкан, җил, иген образларын күрсәтү. (Рәсемнәр куллану). |

| | | |
|---|---|---|
| | | Дид. уен “Дөрес тез!” |
| **декабрь** | | |
| 9.”Башак” . Украин халык әкияте. | Украин халык әкиятен сәхнәләштерү буенча эшне дәвам итү. Декорация төшенчәсен аңлауларына ирешү.<br>Әкияттәге геройларның тотышларын тасвилап уйнарга өйрәтү. Мимика һәм хәрәкәтләр аша эмоциональ хисләр тәрбияләү.Үз-үзләренә бикләнү һәм киеренкелекне җиңәргә булышу. | Декорация белән танышу: рәсемнәр карау.<br>Артикуляцион гимнастика “Елмаю”, “Песи баласы сөт ялый”, “Маятник”.<br>Сулыш гимнастикасы “Яфраклар оча”<br>Ритмопластика “Башаклар”<br>Уенлы күнегү “Яңгыр” ( К.В. Закирова “Уйный-уйный үсәбез”, 160б.)<br>“Башак” әкияте буенча репетициясе. |
| 11.Кыш. ”Куян өе” әкияте. | Яңа әкият белән таныша башлау. Сөйләм телен үстерү, матурлыкны күрә белергә өйрәтү. | Сулыш алу гимнастикасы: карлар оча.<br>Әңгәмә “Кыш көне”<br>Рәсем карау “Кышкы урман”<br>Уен “Дәвам ит һәм күрсәт”<br>Җырлы-биюле уен “Кар бөртекләре”<br>Аудиоязма тыңлау. |
| 12.”Куян өе” әкияте. | Яңа әкият белән танышуны дәвам итү. Бәйләнешле сөйләм телен һәм күзәтүчәнлекне , пантомима күнекмәләрен үстерү. Рухи күтәренкелек тәрбияләү. | Сулыш алу күнегүләре: мамык шарларын тәгәрәтү.<br>Әкият буенча рәсемнәр карау, сорауларга җавап бирү.<br>Уен –пантомима “Әкияттә кунакта” (Карточкаларда Убырлы карчык, Кызыл калфак...геройлары рәсемнәре. Аның кебек ашау, йөрү, утыру, көзгегә карау....) |
| 13.”Куян өе” әкиятен сәхнәләштерү. | Әкиятне сәхнәләштерү осталыгын сүтерүне дәвам итү.Диалогларны эмоциональ җиткерүгә ирешү, интонация, гәүдә позициясенә игътибар итү, хәрәкәтләрне камилләштерү. Сөйләм телен баету, үзара белән килешеп эшләргә өйрәтү. Үз-үзләренә бикләнү һәм киеренкелекне җиңәргә | Артикуляцион һәм сулыш гимнастикасы: “Минем арттан кабатлагыз!”<br>Пантомима “Хайваннар торышы”<br>Уен “Күңелле концерт” (Петрова Т.И. Сергеева Е.Л. Театрализованная игра. 48бит) |

| | | |
|---|---|---|
| | булышу. | |
| **гыйнвар** | | |
| 14.Сюжетлы-рольле уен “Театрга бару” | Балаларда театр, анда эшләүчеләр турындагы күзаллауларын ныгыту. Үз-үзеңне тоту күнекмәләренә өйрәтү. Уенга катнашу теләге уяту. | Әңгәмә “Кунак бул-тыйнак бул!”<br>Сүзтезмә өйрәнү “Театр яктылыкка, нурга илтә”<br>Уенлы күнегү “Театрга бару” |
| 15. ”Бакчада кунаклар” | “Әкият” курчак театры белән таныштыру. Сөйләм телен үстерү. | Иллюстрацияләр карау.<br>Әңгәмә<br>Курчак театры карау. |
| **февраль** | | |
| 16.Муса Җәлил “Күке”, “Әтәч”,”Маэмай”, “Куян” шигырьләре. | Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру. Рольләрне бүлү, образларның характерларын ачыклау. Тыңлый белү, сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләрен үстерү. Шагыйрь иҗатына кызыксыну уяту. | Презентация: «М. Җәлил – балалар дусты”<br>Шигырьләр уку, тыңлау, өйрәнү.<br>Уенлы күнегү “Мин әтәч.....” |
| 17. М. Җәлил “Кызыл ромашка” | Шигырьнең эчтәлеген аңларга булышу, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.Музыканы тыңлау, аңа туры китереп хәрәкәтләр ясауга ирешү. Батырлык хисе тәрбияләү. | Тизәйткеч ятлау:<br>Бер ромашка<br>Үскән ташта.<br>Андый ромашка<br>Юк башка.<br>Аудиоязма тыңлау.<br>Уенлы күнегү “Без – ромашклар”<br>Җырлы-биюле уен “Ромашкалар” |
| 18. М. Җәлил “Сәгать” шигыре. | Җырны игътибар белән тыңлау. Фикер алышу.Сәнгатьле сөйләүгә булган омтылышларын, хәтер сәләтен үстерү. Дикция һәм темп өстендә эш, игътибарлылык тәрбияләү. | Табышмакка җавап табу.<br>Җыр тыңлау.<br>Фикер алышу, сөйләшү.<br>Хәр уен “Сәгать” |
| 19. “Муса Җәлил-балалар дусты” (Иҗади чара) | М.Җәлил, иҗаты турында белемнәрне гомумиләштерү. Сәнгатьле сөйләү күнекмәләрен камилләштерү. Җырлар, уеннар, әсәрләр сәхнәләштерү аша балаларның күңелләрен үстерү, бәйрәм рухы тудыру. | Иҗади чара барышы:<br>- презентация карау;<br>- җырлар җырлау;<br>- уеннар уйнау;<br>- әсәрләрен сәхнәләштереп сөйләү. |

| | | |
|---|---|---|
| **март** | | |
| 20.”Яз җитте”. ”Әнигә бүләк” әкияте. | Яз турында күзаллауларын баету. Сүзлек запасын арттыру. Уен, проблемалы ситуацияләр аша балаларда уңай мөнәсәбәтләр, җаваплылык, кызгану хисе тәрбияләү. | Әңгәмә. “Яз җитте”<br>Тизәйткеч: Яш-яш кояш<br>Якты кояш.<br>Яш-яш кояш<br>Яхшы кояш.<br>Ленталар белән күнегү: “Кояш нурлары”<br>Әкиятне фланелеграфта сөйләп күрсәтү. |
| 21.”Әнигә бүләк” әкияте. | баланың шәхси һәм иҗади потенциалын исәпкә алып, балаларның коммуникатив сәләтен үстерү; балаларда театральләштерелгән эшчәнлеккә кызыксыну формалаштыру. | Сулыш гимнастикас “Көймә йөздерү”<br>Йөзә көймә,<br>Куркып куям:<br>“Җилләр күккә чөймәсме?” (Л. Лерон)<br>Уен “Тавышны үзгәрт”<br>Әкият буенча эшләү: эчтәлеген аңлау, фикер алышу, рольләрне бүлү. |
| 22. ”Әнигә бүләк” әкияте. | Хайваннар хәрәкәтен, аваз ияртемнәрен ныгыту, дөрес әйтергә, йөрергә, өйрәтү буенча күнегүләр башкару. Уенда балаларда мөстәкыйльлек бирү, иҗади сәләтләрен үстерү. | Авазлар әйтелешенә күнегү: ”Тау”<br>Әйдәгез тауга барыйк,<br>Күңел ачып алыйк”. (Тел очы белән аскы тешләргә таяну, телнең урта өлешен күтәрү).<br>Репетиция. |
| 23. ”Әнигә бүләк” әкияте. | Тамаша уйнау осталыкларын һәм диалогик сөйләм телен үстерү. | Әкиятне әниләргә күрсәтү. |
| **апрель** | | |
| 24.Без Тукайны яратабыз. "Кәҗә белән сарык” әкияте. | Г. Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү. Эчтәлек буенча үз фикерләрен әйтә белү. | Г. Тукай портретын карау, сөйләшү.<br>Сулыш гимнастикасы “Станкандагы су”<br>Бармак уены.”Кәҗәкәй”<br>Кәҗә, кәҗә, кәҗәкәй,<br>Минем кызым (улым) бәләкәй,<br>Ул – акыллы, ул – тәтәй,<br>Тимә аңа кәҗәкәй.<br>Театральләштерелгән "Кәҗә белән сарык” әкияте карау.<br>Сорау-җавап. |
| 25.Сәхнәләштерү Г. Тукай “Бала | Балаларда оештыру һәм алып баручы ролен башкару | Пантомима “Матур бакчада” |

| | | |
|---|---|---|
| белән күбәләк” | осталыгын формалаштыру. Г. Тукай әсәрләренә карата кызыксыну тәрбияләү. | Уенлы күнегү “Күбәләкләр оча”<br>Сәхнәләштерү. |
| 26.Г. Тукай «Гали белән кәҗә”, “Бичара куян” | Бибабо курчаклары белән танышуны дәвам итү. Шигырьләр буенча тамаша уйнау сәләтләрен үстерүне дәвам итү. Дуслык һәм кызгану хисләрен тәрбияләү. | Тизәйткеч:<br>Без дә таптык шәт кәҗә.<br>Әби әйтә: шәп кәҗә!<br>Мультфильмнар карау.<br>Фикер алышу.<br>Образларны барлау.<br>Җырлы-биюле уен “Ак куян” |
| 27.Г. Тукай “Ел фасыллары” | Зур булмаган шигырьләрне рольләргә бүлек башкаруны дәвам итү. Телнең сәнгатьлелеген үстерү, интонация, гәүдә торышларына игътибар итү. Табигатьнең матрулыгын тоя белергә, соклану хисләре тәрбияләү. | Табышмакларга җавап бирү.<br>Пантомима “Ел фасылын сурәтләү”<br>Ел фасыллары буенча иллюстрацияләрне күзәтү.<br>Шигырьләрне сөйләү. |
| | **май** | |
| 28.Театр төрләре | Театр төрләре белән таныштыруны дәвам итү (шәүлә театры). Театр сәнгатенә кызыксынуны үстерү. Авазлар әйтелешен камилләштерү. Дуслык хисе тәрбияләү. | Аваз әйтелешенә күнегү, тизәйткеч:<br>Ша-ша-Шамил шар кабарта,Ша-ша- Шамил шар суга,Ша-ша-Шамил ялкау булма,Ша-ша – Шамил бар суга.<br>Әңгәмә һәм театр төрләрен күзәтү.<br>Шәүлә театры һәм мультфильм карау: “Могҗиза”<br>Җырлы-биюле уен “Бармаклар биюе”<br>Хәр. уен “Куллар” ( К.В. Закирова “Уйный-уйный үсәбез”, 163б.) |
| 29.Театр эшчәнлеге төрләре белән танышу. (битлек театры) | Балаларны театр эшчәнлеге төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Битлек театры белән таныштыру | Артикуляция гимнастикасы “Фил”, “Елмаю”, “Шар”<br>“Шарны тиз-тиз кабартам, Һәм һавасын чыгарам”.<br>Битлек театры белән танышу.<br>Битлек театры карау.<br>Битлекләр ясау, уйнау. |

| | | |
|---|---|---|
| 30.Театр эшчәнлеге төрләре белән танышу. (перчатка театры) | Балаларны театр эшчәнлеге төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Алар белән уйнарга кызыксыну уяту. Театр төре өчен кирәк булган күнекмәләргә өйрәтү | Бармак уены “Бармак кайда булдың?” Хәр уен “Һәркайсының үз эше” Перчатка театры кую: “Чуар тавык” әкияте. |
| 31. Театрда кунакта. | Ел дәвамында сәхнәләштергән экитләрне, театраль күренешләрне искә төшерү. Театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү. Нәтҗәне күреп сөенү хисен үстерү. | Әңгәмә. Видеоязмалар карау. |

**“Нәни артистлар” түгәрәгенә йөрүче балаларның күрсәткечен билгеләүче таблица**

| № | Баланың исеме | Сәнгатьле сөйләм | | Авазлар әйтелеше | | Дикция | | Тавыш көче | | Хәрәкәт координациясе | | Уртач балл | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ел башы | ел ахыры | ел башы | ел ахыры | ел башы | ел ахыры | ел башы | ел ахыры | ел башы | ел ахыры | ел башы | ел ахыры |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

1 балл-“Түбән”
2 балл- “Уртача”
3 балл-“Югары”

**Файдаланылган әдәбият:**


1.Балалар бакчасында проект эшчәнлеге. Методик кулланма.- Яр Чаллы: “Мәгълүмати-методик үзәк”, 2012.

2.Дөрес сөйләшик. Методик кулланма.- Казан:РИЦ «Школа», 1999.

3. Губанова Н.Ф. Развитие игровой деятельности: Вторая младшая группа раннего возраста.- М.МОЗАЙКА-СИНТЕЗ, 2016.

4. Закирова К.В. Әхлак нигезе- матур гадәт: Методик кулланма/К.В. Закирова, Р. Ә. Кадыйрова. – Казан, Мәгариф, 2004.

5. Закирова К. В., Мортазина Л.Р. Әй уйныйбыз, уйныйбыз...Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен кулланма. - Казан, Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

6.Закирова К. В. “Балачак-уйнап- көлеп үсәр чак”: методик кулланма. –Казан: Редакционно-издательский центр, 2012.

7. Зарипова З.М., Исаева Р.С. Үстерешле уеннар: методик кулланма.- Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

8.Петрова Т.И., Сергеева Е.Л., Петрова Е.С. Театрализованная игра в детском саду: Разработки занятий для всех возрастных групп с методическими рекомендациями.М.: Школьная Пресса, 2000.

9.Щеткин А.В. Театральная деятельность в детском саду. Для занятий с детьми 4-5 лет/Под ре. О.Ф.горбуновой.- 2-е изд. Испр. – М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ,2022.- 120 с.

В данном документе прошито,
пронумеровано и скреплено печатью:
10 листов
Заведующий Р.Х.Исламова